# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2023 елның «11» октябре

№ 125

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе турында» 2019 елның 01 ноябрендәге 180 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»гы 31.07.2023 ел № 389-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү тәртибе, ставкалары турында» 2019 елның 01 ноябрендәге 180 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге советы карарына (2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы Өтәшкә авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата 0,3% шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган участоклар;».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

3. Әлеге карарны 2023 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (мәдәният йорты бинасы)

**Өтәшкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **А. А. Клопов**